# Ел фасыллары



1. ***Нокталар урынына тиешле ел фасыллары исемнәрен әйтегез.***

Кем дөньяда яшәргәнне ярата, шуңа ... ошый.

Кем чәчәкләргә, яшеллеккә соклана, шул ... ярата.

Алтын ... җитте: уңышлар җыеп алынды.

Яңа ел бәйрәме ... җиткәч була.



# Ел фасыллары



Кем дөньяда яшәргәнне ярата, шуңа яз ошый.

Кем чәчәкләргә, яшеллеккә соклана, шул җәйне ярата.

Алтын көз җитте: уңышлар җыеп алынды.

Яңа ел бәйрәме кыш җиткәч була.





# 2.*Диалогны дәвам итегез.*

- Яңгыр явамы?
- ...
- Синең зонтигың бармы?
- ...
- Минем дә зонтигым бар. Әйдә киттек.
- ...

# 3. Текс өстендә эш.

Көз- табигатьнең бик матур вакыты.

Минем әнием- җәйне, әтием- кышны,энем язны ярата. Мин көзне яратам. Табигатьнең һәр фасылы үзенчә матур, ә миңа көз ныграк ошый.Көз көне без мәктәпкә барабыз, дуслар белән очрашабыз. Көз- елның иң бай вакыты. Ул- яшелчәләр, җиләк- җимешләр өлгергән вакыт.

Көз ахырында көннәр салкыная, яңгырлар ява, җил исә, кошлар җылы якка китә. Безнең якларда көз менә шундый.

*4.Тиешле сүзләрне куеп, җөмләләрне укыгыз.*

Менә көз ... .

Агачлардан сары яфраклар ... .

Салкын җил ... .

Көз көне карлар, яңгырлар ... .

Кошлар җылы якларга ... .

*Терәк сүзләр*: ява, җитте, исә, китteләр, коела.





Менә көз җитте .

Агачлардан сары яфраклар коела .

Салкын җил исә .

Көз көне карлар, яңгырлар ява .

Кошлар җылы якларга киттеләр .



# Елның дүрт фасылы.

## Бу кайчак була?

Боз һәм кар эреде,
Сулар йөгерде,
Еглап елгалар,
Яшьләр түгелде;
Көннәр озая,
Төннәр кыскара.
Бу кайсы вакыт?
Я, әйтеп кара.



Ашлыклар үсте,
Башаклар пеште,
Кояш пешерә,
Тиргә төшерә.
Халык ашыга
Китә басуга,
Урагын ура,-
Бу кайчак була?



Кырлар буш кала,
Яңгырлар ява,
Җирләр дымлана,-
Бу кайчак була?



Һәр җир каралган,
Сулар бозланган,-
Уйный җил, буран,-
Бу кайчак була?

